ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422645С.Большой Салтан,
ул. Р.Шарафеева, дом 59

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422645, Олы Солтан авылы,
Р.Шәрәфи урамы, 59 нчы йорт

Тел.: (84361) 27542, факс: (84361) 27542, e-mail: Bslt.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2018г. Олы Солтан авылы № 16Б

2431 кв.м. мәйдандагы №16:34:091101:98 кадастр номеры белән, 58144 кв.м. мәйдандагы №16:34:091101:295 кадастр номеры белән булган җир кишәрлегендә АЗС һәм керү юллары урнаштыру өлешендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Генераль планы проектына үзгәрешләр кертү буенча фикер алышуга гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Солтан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкының гавами тыңлаулар уздыру юлы белән генераль планнар проекты турында фикер алышуда катнашу хокукын үтәү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. 2431 кв.м. мәйдандагы №16:34:091101:98 кадастр номеры белән, 58144 кв.м. мәйдандагы №16:34:091101:295 кадастр номеры белән булган җир кишәрлегендә АЗС һәм керү юллары урнаштыру өлешендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Генераль планы проектына үзгәрешләр кертү буенча (алга таба генераль планга үзгәреш кертү) фикер алышуга гавами тыңлауларны 2018 елның 23 ноябренә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Генераль планы проекты на үзгәрешләр кертү буенча фикер алышуга гавами тыңлауларны 2018 елның 23 ноябренә 14.00 сәг.тә Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Олы Солтан авылы Р.Шәрәфеев урамы 59 йорт адресы буенча урнашкан авыл культура йортында үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Башкарма комитетына:
   3.1. 2018 елның 10 ноябренә кадәр әлеге карарны халыкка җиткерергә

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча булган материалларны түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендлта: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфеев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга;

3.2 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Генераль планы проектына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышуга гавами тыңлауларда генераль план проектын эшләүчеләрне («Татинвестгражданпроект» ДУП) катнашуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Генераль планы проектына үзгәрешләр кертү буенча булган тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен исәп, гомумиләштерү һәм карау буенча беркетелә торган эш төркемен төзергә һәм расларга.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Генераль планы проектына үзгәрешләр кертү буенча гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенә Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфеев урамы, 12 йорт адресы буенча, гражданнарның исеме, фамилиясе , атасының исеме, туган елы, адресы күрсәтелеп, язма рәвештә кертелә

6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Генераль планы проектына үзгәрешләр кертү буенча карар кабул итү яки үзгәрешләр кертүне кире кагу һәм эшләп бетерү өчен, Генераль план проектына үзгәреш кертү буенча булган гавами тыңлауларның протоколын һәм нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советына җибәрергә.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000725
ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Р 06-601/02